РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«21» декабря 2023 г. г. Альметьевск № 268

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 414 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында бюджет процессы турында нигезләмә хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында, Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору, Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану һәм 2023 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2022 елның 21 ноябрендәге 448-ФЗ номерлы, 2023 елның 2 ноябрендәге 520-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 96.6 һәм 220.1 статьяларына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында, Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм 2024 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» Федераль законнар нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында бюджет процессы турында нигезләмә хакында» 2014 елның 19 ноябрендәге 414 номерлы Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы карарына кушымтага (2015 елның 23 октябрендәге 17 номерлы, 2016 елның 6 октябрендәге 90 номерлы, 2016 елның 28 декабрендәге 144 номерлы, 2018 елның 28 декабрендәге 269 номерлы, 2019 елның 29 апрелендәге 289 номерлы, 2019 елның 25 октябрендәге 328 номерлы, 2021 елның 12 маендагы 50 номерлы, 2021 елның 15 ноябрендәге 86 номерлы, 2022 елның 13 июлендәге 148 номерлы, 2022 елның 28 декабрендәге 189 номерлы, 2023 елның 17 маендагы 218 номерлы, 2023 елның 6 июлендәге 222 номерлы, 2023 елның 2 ноябрендәге 249 номерлы карарлар нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлекнең 12 статьясындагы өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Башкарма комитетның резерв фонды күләме район бюджеты турында район Советы карары белән билгеләнә.».

2. 2024 елның 1 январеннан 2025 елның 1 яннварена кадәр 1 бүлекнең 19.1 статьясының 3 пунктының, 19.2 статьясының 3 пунктының гамәлдә булуын туктатып

торырга (муниципаль гарантияләрне бюджет турындагы карар нигезендә бирү өлешендә).

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының бюджет-финанс мәсьәләләре, салымнар һәм җыемнар буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Грушин А.И.).

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов

«СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА»